РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Село Янурусово, улица Ленина, дом 43а,
423370 Телефон 4-10-19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
Ленин урамы,43 а йорт, Янурыс авылы,
423370 Телефон: 4-10-19

ОГРН 1031604000757 ИНН/КПП 1636001403/163601001 ОКАТО 92253884000

**РЕШЕНИЕ**
**«12» декабрь 2019 ел.**

**КАРАР**
**№ 27**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Сарман муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү кагыйдәләрен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге Карарның нигезләмәләре бюджетларны төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2020 ел бюджетыннан башлап 2021 һәм 2022 елларның план чорына кадәр кулланыла.

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында әлеге карарны бастырып чыгарырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Янурыс авыл җирлеге
Советы Рәисе — А. Ә. Мөхәммәдиева

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге Советы карарына 1 нче кушымта «12» декабрь 2019 ел № 27

Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Сарман муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү кагыйдәләре

1.Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр Сарман муниципаль районы бюджетына (алга таба - район) Сарман муниципаль районы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында бирелә (алга таба - субсидияләр).

2. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләренең баш бүлүчесе булып Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге Башкарма комитеты тора.

3. Субсидияләр Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге Башкарма комитетына әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидияләр бирү шартлары түбәндәгеләр:

район бюджетында (район бюджетының җыелма бюджет язмасы) районның финанслашу максатларында аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә субсидия бирелгән чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу, шул исәптән аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирүне планлаштырыла торган күләмне дә кертеп;

Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге бюджетыннан район бюджетына субсидияләр бирү турында килешү төзү (алга таба – килешү).

5. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максат билгеләнеше;

б) субсидия бирү шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

6. Килешүгә Сарман муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе һәм җирлек башкарма комитеты җитәкчесе кул куя.

7. Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге Советы карарына агымдагы финанс елына һәм план чорына Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге бюджеты турында карар кертелгән очракта, алар субсидия бирүгә

бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен тиешле финанс елында төгәлләштерүне күздә тота, Килешүгә тиешле үзгәрешләр кертелә.

8. Субсидия алу өчен районның башкарма комитеты субсидияләр бирүгә гариза бирә.

9. Район бюджетына бирелә торган субсидия күләме Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге бюджетының керем мөмкинлекләреннән чыгып билгеләнгән субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләменең әһәмиятенә, район бюджеты ихтыяҗының финанс ярдәме күрсәтүгә ихтыяҗы күләменең әһәмиятенә карап билгеләнә.

10. Субсидияләр Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Башкарма комитеты тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең район бюджетына килешү белән билгеләнә торган срокларда район бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачык территориаль органы счетына күчерелә.

11. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлеше Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә җирлек бюджеты керемендә кайтарылырга тиеш.

12. Район тарафыннан субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү килешүдә билгеләнгән күрсәткечләрне чагыштыру һәм субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренең асылда ирешелгән күрсәткечләрен чагыштырып, Сарман муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Районның җирле үзидарә органнары Сарман муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына район бюджетының чыгымнары турында хисап бирәләр, аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия тора.